| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 70 "26" 01 2022 ел

2022 елның I кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең һәм мөлкәт бәясенең чик күрсәткечләрен раслау турында

Торак кодексының 49,51 статьясы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы белән югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында" 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы боерыгы, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 630 номерлы карары нигезендә, Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне расларга:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы бусагасы:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 729944 сум;

1.1.2.Ике кешелек гаилә өчен һәм 1 729944 сумнан артык сумма гаилә әгъзалары санына арта.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче граждан өчен - 16 731,76 сум;

1.2.2.2.Ике кешелек гаилә өчен һәм 16 731,76 сумнан артык сумма гаилә әгъзалары санына арта.

2. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә, Спас муниципаль районы Болгар шәһәр башкарма комитетына торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: В.А. Осокин